| | |
|---|---|
| **Республика Татарстан**<br>**СОВЕТ**<br>**ШАРЛИАРЕМИНСКОГО**<br>**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**<br>**САРМАНОВСКОГО**<br>**МУНИЦИПАЛЬНОГО**<br>**РАЙОНА** | **Татарстан Республикасы**<br><br>**САРМАН**<br>**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**<br>**ЧУКМАРЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**<br>**СОВЕТЫ** |

| | |
|---|---|
| **РЕШЕНИЕ**<br>**2018елның 24 сентябре** | **КАРАР**<br>**№ 19** |

**Гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Чукмарлы авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22 ст., 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, Чукмарлы авыл җирлеге Уставының 11 статьясы, «Референдум уздыруны инициацияләү турында» 2018 елның 17 сентябрендәге 73 номерлы карары нигезендә, Чукмарлы авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Чукмарлы авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча 2018 елның 18 ноябренә җирле референдум билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга:

"2019 елда үзара салым чараларын Чукмарлы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә кертүгә сез килешәсезме, моңа I төркем инвалидларыннан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән дә килешәсезме:

Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен тикшереп тору, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру, шул исәптән:

- Чукмарлы, Нарат-Асты авылы янындагы артезиан скважиналары территориясен ремонтлау, буяу һәм киртәләү эшләре өчен төзелеш материаллары сатып алу һәм түләү;

- территорияне чистарту (үләнне чаптыру, куакларны һәм агачларны кисү) Чукмарлы авылы, Нарат-Асты авылы.

ӘЙЕ ЮК

3. Мәгълүмат стендларында һәм Чукмарлы авыл җирлегенең рәсми сайтында кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә әлеге карарны игълан итәргә.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Чукмарлы авыл җирлеге
Советы рәисе И.Х.Хадиуллин